# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасы Конституциясенең 89, 94 , 101, 111 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

1 статья. Татарстан Республикасы Конституциясенең 89, 94, 101, 111 статьяларына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, №9-10; 1994, №11; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1995, №2-3, №12; 1996, №11; 1999, №6; 1999, №8 (1 өлеш)) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. 89 статьяның икенче өлешенә түбәндәге эчтәлекле яңа 19 пунктны өстәргә:

«19) Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил сайлау;»

2. 89 статьяның 2 өлешендәге 19-29 пунктларын 20-30 пунктлары дип санарга.

3. 89 статьяның өченче өлешенә түбәндәге эчтәлекле яңа 15 пунктны өстәргә:

«15) Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил сайлау;».

4. 89 статьяның өченче өлешендәге 15-18 пунктларын 16-19 пунктлары дип санарга.

5. 94 статьяга «Татарстан Республикасы Прокуроры,» сүзләреннән соң «кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауны тәэмин итү мәсьәләләрендә Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил,» сүзләрен өстәргә.

6. 101 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 3 пунктны өстәргә:

«3) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил урынына кандидатура тәкъдим итә;».

7. 101 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктын 4 пункты дип санарга.

8. 111 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 пунктны өстәргә:

«6) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил урынына кандидатура тәкъдим итә;».

9. 111 статьяның 6-19 пунктларын 7-20 пунктлары дип санарга.

2 статья. Әлеге Законны матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты
М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2000 елның 3 марты
№ 93